КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 24 ноябрь г.Казань № 899

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсы турында» 2015 ел, 30 апрель, 305 нче карары белән расланган «Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсы турында» 2015 ел, 30 апрель, 305 нче карары белән расланган «Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсы турындагы нигезләмәгә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 апрель, 305 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 24 ноябрь, 899 нчы
карары редакциясендә)

# «Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсы турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә «Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсының (алга таба – Конкурс) үткәрү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Конкурс ел саен 1 июньнән 1 сентябрьгә кадәр үткәрелә.

1.3. Конкурсның оештыручысы – Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның төп максатлары түбәндәгеләр:

халыкны әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләрен хәл итүгә тарту;

яшь кешеләргә экология өлкәсендәге мәсьәләләргә карата үз мөнәсәбәтен белдерү мөмкинлеге бирү;

яшь талантларны Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясендә социаль экологик реклама булдыруга җәлеп итү.

2.2. Конкурсның төп бурычлары түбәндәгеләр:

яшь кешеләрдә әйләнә-тирә мохиткә карата сакчыл мөнәсәбәт принципларын формалаштыруга булышлык күрсәтү;

яшьләрне социаль иҗат итү, әхлакый тәрбия һәм гражданлык тәрбиясе бирү өлкәсенә җәлеп итү;

яшьләр тарафыннан экологик мәсьәләләрне хәл итүгә үз өлешен кертү кирәклеген аңлау;

Конкурста катнашучыларның социаль эшләрен белем бирү оешмаларында, массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру юлы белән яшьләрнең экологик культурасын арттыру.

## 3. Конкурс номинацияләре һәм конкурс эшләренә карата таләпләр

3.1. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Социаль плакат» – ике яшь категориясендә:

кече – 5 яшьтән алып 14 яшькә кадәр;

өлкән – 5 яшьтән алып 35 яшькә кадәр;

«Фотосурәт» – ике яшь категориясендә:

кече – 5 яшьтән алып 14 яшькә кадәр;

өлкән – 5 яшьтән алып 35 яшькә кадәр;

«Социаль видеоролик»;

«Кыска метражлы фильм»;

югарыда күрсәтеп үтелгән барлык номинацияләрдә һәм яшь категорияләрендә «Халык тавыш бирүендә җиңүче».

3.2. Конкурс эшләрендә атмосфера һавасын, су һәм җир ресурсларын саклау өлкәсендә, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү тармагында, шулай ук үсеп килүче буынга экологик тәрбия бирү һәм белем бирү мәсьәләләрендә Россия Федерациясе өчен экология буенча аеруча актуаль мәсьәләләрне хәл итү юлларын, вариантларын, идеяләрен, аларга якын килүне чагылдырырга кирәк.

3.3. Конкурс эшләренә карата техник таләпләр:

1) «Социаль плакат» номинациясендә:

плакат макеты (плакатлар серияләре, 10 файлдан артыграк булмаган) JPEG форматында кимендә 300 dpi ачыклану дәрәҗәсе белән тәкъдим ителергә, А4 форматында бастыру өчен яраклы булырга тиеш, файл 10 МБ тан артмаска тиеш;

плакатта слоган урнаштырылырга мөмкин;

эшкә аның кыскача тасвирламасы теркәлә (20 сүздән артыграк булмаган).

Кеше яшь категориясендә кулдан эшләнгән яки компьютер графикасы ярдәмендә башкарылган эшләр кабул ителә. Кулдан эшләнгән плакатлар фотосурәткә төшерелә яки сканердан чыгарыла.

Өлкән яшь категориясендә график программалар әсбаплары ярдәмендә башкарылган эшләр кабул ителә;

«Фотосурәт» номинациясендә:

фотосурәт (фотосурәтләр сериясе, 10 файлдан артыграк булмаган) JPEG форматында кимендә 300 dpi ачыклану дәрәҗәсе белән тәкъдим ителергә, А4 форматында бастыру өчен яраклы булырга тиеш, файл 10 МБ тан артмаска тиеш;

фотосурәттә язулар һәм слоганнар урнаштырылмаска тиеш;

эшкә аның кыскача тасвирламасы теркәлә (20 сүздән артыграк булмаган);

«Социаль видеоролик» һәм «Кыска метражлы фильм» номинацияләрендә:

видео MP4 форматында тапшырыла, файл 150 МБ тан артмаска тиеш;

видео башланганда түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

Конкурс (Конкурс логотипын кулланып), эш исеме, авторның (авторлар коллективының) фамилиясе, исеме, төбәк, торак пункт атамасы;

социаль видероликның хронометражы – 30 секундтан артыграк булмаган;

кыска метражлы фильмның хронометражы – 5 минуттан артыграк булмаган;

һәр эшкә сценариенең текст тасвирламасы бирелә.

## 4. Конкурста катнашу шартлары

4.1. Конкурста катнашучылар – 5 яшьтән алып 35 яшькә кадәр (35 яшьне кертеп) Россия Федерациясе гражданнары (аерым авторлар һәм коллективлар).

Конкурста катнашуга дәгъва итүчеләрнең һәрберсе һәр номинация буенча 5 тән дә артыграк булмаган гариза тапшырырга мөмкин.

4.2. Конкурста катнашу өчен түбәндәгеләрне башкарырга кирәк:

Конкурсның рәсми сайтында: https://чистыйвзгляд.рф (алга таба – Конкурсның рәсми сайты) теркәлергә;

Конкурсның рәсми сайтында гариза һәм конкурс эшен тапшырырга.

4.3. Гариза һәм конкурс эше кергән көннән 10 көн эчендә катнашучыга конкурс эшенә Конкурста катнашырга рөхсәт итү турында яки, баш тартуның сәбәбен күрсәтеп, Конкурста катнашырга рөхсәт итмәү турында хәбәр килә.

4.4. Түбәндәге очракларда Конкурста катнашырга рөхсәт ителми:

конкурс эше бу Нигезләмәнең 3.2 нче һәм 3.3 нче пунктлары таләпләренә туры килмәгән;

конкурс эшендә дөрес булмаган белешмәләр булган;

конкурс эшендә плагиат булган;

әгәр дә конкурс эшенең эчтәлеге, сюжеты, сәхнәдәге затлар һәм персонажлар гамәле Россия Федерациясе законнарына каршы килсә;

әгәр дә конкурс эше элегрәк моңа охшаш конкурсларда призлы урыннар алган булса.

4.5. Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән эшләр конкурс эшен кабул итү турында хәбәр җибәрелгән көннән өч көн эчендә гомуми тавыш бирү өчен Конкурсның рәсми сайтында урнаштырыла.

4.6. Номинацияләрнең һәркайсында иң күп тавыш җыйган конкурс эшләре халык тавыш бирүендә җиңүчеләр дип танылa һәм эксперт комиссиясе тарафыннан җиңүчеләрне сайлауда катнашмый.

Әгәр дә бер автор ике яки аннан да күбрәк номинациядә иң күп тавыш җыйган булса, ул күбрәк тавыш җыйган номинациядә җиңүче дип танылa, башка номинациядә аннан соң килгән катнашучы җиңә.

4.7. Конкурсның бер номинациясендә җиңгән автор Конкурсның башка номинацияләрендә җиңүче исеменә дәгъва итә алмый.

4.8. Конкурста катнашкан өчен түләү алынмый.

## 5. Конкурсның оештыручысы

5.1. Конкурсның оештыручысы:

эксперт комиссиясен оештыра;

катнашучыларга Конкурсны үткәрү шартлары турындагы мәгълүматны үз вакытында хәбәр итә;

конкурс эшләренә Конкурста катнашырга рөхсәт итү турында яки Конкурста катнашырга рөхсәт итмәү турында карарлар кабул итә;

Конкурс үткәрү барышы һәм аның йомгаклары турында массакүләм мәгълүмат чараларына мәгълүмат бирә;

эксперт комиссиясенең Конкурс йомгаклары турындагы карарын раслый;

Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыра.

## 6. Эксперт комиссиясе

6.1. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү һәм аңа йомгаклар ясау өчен эксперт комиссиясе төзелә, аның составы ел саен Конкурс оештыручы боерыгы белән раслана.

6.2. Эксперт комиссиясе Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, иҗтимагый оешмалар, фәнни берләшмә, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләреннән формалаша.

6.3. Эксперт комиссиясе ел саен 15 сентябрьгә кадәр утырышта конкурс эшләрен карый һәм конкурс комиссиясе әгъзалары утырышында катнашучыларның күпчелек тавышлары белән, ачык тавыш биреп, һәр номинация буенча Конкурста җиңүчеләрне билгели.

6.4. Эксперт комиссиясе әгъзаларының тавышлары тигез булган очракта, эксперт комиссиясе рәисе яки аның урынын биләүче зат тавышы хәлиткеч була.

6.5. Эксперт комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа рәис яки аның урынын биләүче зат һәм конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кул куела.

## 7. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

7.1. Конкурс эшләре эксперт комиссиясе тарафыннан түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

конкурс эшенең дәлилле булуы һәм эчтәлегенең ачылу тирәнлеге;

чишелешнең оста бирелеше, реклама, социаль методикалар һәм технологияләрнең нәтиҗәлелеге;

конкурс эшенең социаль әһәмиятлелеге, позитивлыгы һәм креативлыгы (идея яңалыгы, үзенчәлекле булуы);

бәян итү теле һәм стиленең төгәл һәм аңлаешлы булуы;

төс, яктылык, шрифт, рәсем, график элементлар, интонация һ.б. җиткерә торган эмоциональ буяулар булуы.

## 8. Җиңүчеләрне бүләкләү

8.1. Конкурста һәр катнашучы Конкурста катнашучы сертификатын электрон рәвештә ала.

8.2. Казан шәһәрендә үткәрелә торган бүләкләү тантанасында Конкурста җиңүчеләргә дипломнар, кубоклар һәм кыйммәтле бүләкләр бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымта нигезендә тапшырыла.

Җиңүчеләрнең бүләкләү тантанасында шәхси катнашуы диплом, приз һәм кубок алуның мәҗбүри шарты булып тора.

8.3. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы ел саен 31 декабрьгә кадәр оештырыла һәм үткәрелә. Конкурсның оештыру комитеты конкурста җиңүчеләргә бүләкләү тантанасын үткәрү көненә кадәр кимендә 7 көн кала чакыру җибәрә.

8.4. Конкурс йомгаклары җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын үткәргән көннән өч көн эчендә Конкурсның рәсми сайтында урнаштырыла.

8.5. Конкурсның оештыручысы түбәндәгеләргә хокуклы:

конкурс эшләрен коммерциячел булмаган максатларда һәм авторга (авторлар коллективына) акчалата бүләкләү түләмичә, әмма автор (автордашлар) исемен мәҗбүри күрсәтеп файдаланырга;

конкурс эшләре базасында (электрон каталог, интернет-ресурслар) тудырылган социаль реклама кампанияләрен үткәрергә;

конкурс эшләрен гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында таратырга;

җәмгыять өчен әһәмиятле чаралар үткәргәндә, Конкурс ихтыяҗлары өчен һәм аны рекламалау максатларында конкурс эшләренә репродукция ясарга;

конкурс эшләрен методик һәм мәгълүмати басмаларда, телерадиокомпанияләр эфирында трансляцияләү өчен, прессада, тышкы реклама йөрткечләрендә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру өчен файдаланырга;

уку-укыту һәм башка максатларда конкурс эшләрен тулысынча яки өлешчә кулланырга.

«Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсы турындагы нигезләмәгә кушымта

«Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсының
приз фондын бүлү

<table>
<tr><td rowspan="4">Урын</td><td colspan="6">Номинация исеме</td></tr>
<tr><td colspan="2">«Социаль плакат»</td><td colspan="2">«Фотосурәт»</td><td rowspan="2">«Социаль видеоролик»</td><td rowspan="2">«Кыска метражлы фильм»</td></tr>
<tr><td colspan="4">Яшь категориясе</td></tr>
<tr><td>кече</td><td>өлкән</td><td>кече</td><td>өлкән</td><td rowspan="2">100000 сумга</td><td rowspan="2">100000 сумга</td></tr>
<tr><td>1</td><td>80000 сумга</td><td>80000 сумга</td><td>80000 сумга</td><td>80000 сумга</td></tr>
<tr><td>2</td><td>50000 сумга</td><td>50000 сумга</td><td>50000 сумга</td><td>50000 сумга</td><td>70000 сумга</td><td>70000 сумга</td></tr>
<tr><td>3</td><td>40000 сумга</td><td>40000 сумга</td><td>40000 сумга</td><td>40000 сумга</td><td>50000 сумга</td><td>50000 сумга</td></tr>
<tr><td>Халык тавыш бирүендә җиңүче</td><td>30000 сумга</td><td>30000 сумга</td><td>30000 сумга</td><td>30000 сумга</td><td>30000 сумга</td><td>30000 сумга</td></tr>
<tr><td colspan="7">Призлы урыннарның гомуми саны – 24</td></tr>
</table>